ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2014 Казан ш. № 10-51/кс

***“Теплосбыт” ҖЧҖ тарафыннан җиткерелә торган кайнар суның ябык системаларындагы кайнар су өчен 2015 елга тарифлар билгеләү турында***

2011 елның 7 декабрендәге “Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында”гы №416-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 маендагы “Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләт көйләве турында”гы №406 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге №468 карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты БОЕРА:

1. Әлеге карарга теркәлүче кушымта буенча “Теплосбыт” ҖЧҖ тарафыннан җиткерелә торган кайнар суның ябык системаларындагы кайнар су өчен 2015 елга календарь бүлгәләп тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. «Теплосбыт» ҖЧҖенә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы №6 карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы көйләү чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң ун көн узгач гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 17.12.2014 ел,
№10-51/кс карарына кушымта

# “Теплосбыт” ҖЧҖ тарафыннан җиткерелә торган кайнар суның ябык системаларындагы кайнар су өчен 2015 елга календарь бүлгәләнгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, кайнар су белән тәэмин итүче оешма исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (ике компонентлы) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Кайнар су компоненты, сум./куб.м | | Җылылык энергиясе компоненты, сум/Гкал | |
| | | 01.01.2015-30.06.2015 | 01.07.2015-31.12.2015 | 01.01.2015-30.06.2015 | 01.07.2015-31.12.2015 |
| | Әгерҗе муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Теплосбыт» ҖЧҖ | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 35,48 | 35,49 | 1383,26 | 1569,64 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 30,07 | 30,08 | 1172,25 | 1330,20 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып күрсәтелә.

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге